Бүгенге санда:



Безнең үз кирпечебез булачак. 5 бит


# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Чәршәмбе 6 май 2015 ел

№ 32 (10561)


**7 майга һава торышы:** болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил төньяк-көнчыгыштан, 6-7 м/с; температура көндез +11°С, төнлә +8°С

## Җиңү календаре

**3**

**БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ – 9 МАЙГА КАДӘР ШУЛКАДӘР ВАКЫТ КАЛДЫ**

Майның беренче көннәрендә Берлин гарнизоны капитуляцияләнә. Берлинны алганнан һәм Германия капитуляцияләнгәннән соң, 6 майда сугышны тәгәлләүче Прага стратегик һөҗүм операциясе башлана, ул 11 майга кадәр дәвам итә. Совет гаскәрләренең барлык көчләре дә Чехословакияне фашист илбасарларыннан азат итүгә юнәлдерелә.

**ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ**

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### КОНКУРСТА КАТНАШАЛАР

Быел районнан 6 фермер хуҗалыгы башлыгы "Гаилә фермаларын үстерү" программасы буенча конкурс сайлап алуында катнашырга теләк белдергән. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында исә конкурска заявкалар һәм документлар кабул итү 24 апрельдән старт алды һәм 21 майга кадәр дәвам итәчәк.

### САЙЛАУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Бүген 14.00 сәгатьтә ТР Дәүләт Советы депутаты Илгиз Салихов сайлаучыларын кабул итә. Аңа 12 нурлатлы язылган.

### БЕРЛИНГА ЮЛ

Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итү кысаларында кино хезмәте күрсәтү бүлеге "Дорога на Берлин" Россия фильмының премьерасын тәкъдим итәчәк. Укучылар өчен ул Мәдәният сараенда 7 майда 13.00да, башкалар өчен 8 майда 17.00дә күрсәтеләчәк. Сугыш ветераннары, локаль хәрби конфликтларда катнашучылар түләүсез кертелә.

### СУ ӘСИРЛЕГЕНДӘ

Дүшәмбе көнне узган яшенле көчле яңгыр аркасында утлар өзелмәсә дә, су басулардан котылып булмаган. Янгын частеннан әйтүләренчә, мондый хәбәрләр "Казанские аптеки"дән кергән, шулай ук шәхси төсмердәгеләр дә булган. Ә кичә редакциягә Сәлимҗанов ур., 19дан шалтыраттылар. Аларның йорты су әсирлегендә калган икән.

**ӘБУНӘ ЧОРЫН ЫЧКЫНДЫРМАГЫЗ!**

Район, республика вакыйгаларыннан хәбәрдар булып торасың килсә, "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу чорын кулдан ычкындырма. Газетага почта бүлекчәләрендә, редакциянең реклама бүлегендә дә язылырга була.

# Бәйрәм хезмәттә үтте



ЯҢА КОМПЛЕКСНЫ ТӘҖРИБӘЛЕ МЕХАНИЗАТОР АЛЕКСАНДР РЯБОВКА ТАПШЫРГАННАР

Автор фотосы

**Район игенчеләре май бәйрәмнәрен басуда оешкан хезмәт белән үткәрделәр. Кичәге көнгә район буенча 15 мең гектардан артыграк мәйданда чәчү үткәрелгән. Бу – барлык мәйданнарның 33 проценты.**

"Агромир" җәмгыятендә дә бу көннәрдә басуларда 5 чәчү агрегаты белән эшлиләр. Шуларның икесе – заманча чәчү комплексы. "Русский вепрь 2000 К" дип аталганын бу язда кыр эшләре алдыннан гына кайтарганнар әле. Аны шулай ук яңа кайтарылган көчле "Нью-Холланд" тракторы белән комплектлап, хуҗалыкның тәҗрибәле механизаторы Александр Рябовка тапшырганнар. Район башлыгы Равил Кузюров һәм районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин хуҗалыкта чәчү эшләренең барышын карарга килгәндә, механизатор арпа чәчү белән мәшгуль иде. Моңа кадәр дә заманча техникада эшләү тәҗрибәсе булган механизатор яңасының үзенчәлекләрен дә тиз өйрәнеп өлгергән.

– Бер шундый чәчү комплексы 3–4 тракторны алмаштыра, – ди "Агромир"ның баш агрономы Андрей Светкин һәм хуҗалыкта чәчү эшләренең үзенчәлекләренә тукталa. – Быел техник культураларның мәйданнарын арттыра төштек. Рапсны 500ләп, көнбагышны 1400 гектарда игәчәкбез. 1200 гектарда уҗым культуралары чәчеп калдырган идек. Аларга да өмет зур.

"Агромир"да исә чәчүлек мәйданнары 9000 гектарга якын тәшкил итә. Кичәге көнгә барлык мәйданнарның 32 процентында язгы чәчү эшләре үткәргәннәр.

Районның башка хуҗалыкларында да эш гөрли. "Сөләйманов Ә.И." КФХсында инде экваторга якынлашып киләләр, биредә барлык мәйданнарның 47, "Южная"да 45, "ИРС"та 33 процентында язгы чәчү эшләре үткәргәннәр. Нигездә бодай, шикәр чөгендере, көнбагыш, кукуруз, берьеллык үләннәр чәчү бара. Район башлыгы исә чәчүне оптималь срокларда башкаруны, эшне һәр җирдә дә икешәр сменада оештыруны шарт итеп куйды.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

ЧАКЫРУ

# Җиңү көне чакыра мәйданга

**9 Май – Бөек Җиңүнең 70 еллыгына районда зур бәйрәм программасы әзерләнә.**

8.00дан 9.30гача үзәк мәйданда театрлаштырылган мәйданчыклар – "Фронт агитбригадасы", "Привал", "Блиндаж", Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарихы төбәк музее, үзәк китапханә күргәзмә стендлары эшләячәк.

**10.00да** Хәтер һәм Дан мемориалына Бөек Ватан сугышында ятып калган якташларыбыз хөрмәтенә веноклар салу. Тантаналы митинг. Зур Җиңү парады. «Үлемсез полк» акциясе.

**11.30да** Үзәк мәйданда күңел ачу чаралары старт алачак. Бәйрәм концерты булачак, сәүдә нокталары, хәрби-кыр кухнясы, Балалар шәһәрчеге эшләячәк, спорт-күңел ачу уеннары үткәреләчәк. Шәһәр Мәдәният сараеның тамаша залында сугыш темасына фильмнар күрсәтү, Кама аръягы һәм Нурлат тарихы төбәк музееның Хәрби Дан заллары буенча экскурсияләр оештырылачак. Бөек Ватан сугышы ветераннары өчен бәйрәм төшке ашы булачак.

Бәйрәм көнне спорт чаралары да көтелә. Шикәрчеләр бистәсе микрорайоны стадионында физик культура коллективлары һәм ветераннар арасында футбол буенча иптәшләрчә очрашу үтәчәк. Якташыбыз, Советлар Союзы Герое А.И.Кузнецов хөрмәтенә традицион җиңел атлетика ярышлары оештырылачак, шахмат турниры үткәреләчәк.

**Җиңү бәйрәме чаралары шәһәрнең үзәк паркында 19.00-22.00гәчә** республика артистлары катнашындагы концерт программасы белән дәвам итәчәк. **22.00дә** – бәйрәм фейерверкы.

8 майда бәйрәм чаралары авыл җирлекләрендә узачак.

МАХСУС РЕЖИМ

# Космостан да күзәтәләр

**Тулаем Татарстандагы кебек үк Нурлатта да янгынга каршы махсус режим дәвам итә. Ул 15 майга кадәр сузылачак, һава торышы көйсез булса, тагы да дәвам итәчәк.**

Теләсә нинди максатларда да учаклар ягу өчен штраф каралган. Бәйрәмнәр алдыннан бу хакта белеп тору зыян итмәс, чөнки штрафларның күләме икеләтә артты.

– Янгынга каршы режимны бозган гражданинга 2000-4000 сум штраф янаса, вазифаи затка 15000-30000, юридик затка 400000-500000 сумга кадәр тәшкил итәчәк, – дип хәбәр итте узган атнадагы видеобрифингта республиканың янгын күзәтчелеге буенча баш дәүләт инспекторы Сергей Сергеев һәм бәйрәм көннәрендә янгын күзәтчелеге службалары тулы әзерлектә булачак, диде.

Әлбәттә, никадәр генә кисәтмәсеннәр, әмма язгы табигать кешеләрне үз кочагына тартып тора. ТР Урман хуҗалыгы министры Алмас Нәзиров урман буйларында җиһазландырылган урыннарда, участок урманчылыкларында ял итәргә була, диде. Мәсәлән, моның өчен һәр елны кечкенә өйләр ясап куялар, әмма анда учак ягарга ярамый. Министр әйтүенчә, шашлык кыздырырга мангал өчен бетонланган урын сайларга, янгынга каршы барлык чараларны да күрергә кирәк.

Шашлыклы ял ут белән көрәшүчеләр өчен бер проблема булса, икенчесе – камыл яну. Сергей Сергеев республика буенча шундый фактлар китерде – 80 очрак теркәлгән инде. Нурлатта да янгынга каршы режимны бозу очраклары бар.

– Быел шундый биш очрак теркәлде, 2014 елда 12 факт булган иде, – диде Нурлат районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенең баш белгече Әлмәрис Талипов. – Күптән түгел генә бер вазифаи затны административ җаваплылыкка тарттык, аңа 15 мең сум штраф салынды.

Безнең районда 7 торак пунктта урман янгыны куркынычы бар. Шуларның 6сында – Заречный, Тумба, Торнаяс, Бутаиха, Юган һәм Единениедә гадәттән тыш хәл очрагына халыкка тавыш сигналы бирү җайланмалары куелган, ул бары тик Кызыл Юлда гына юк, бу поселок әлеге исемлеккә быел гына кертелде әле.

– Әлеге авылларның тирәсе сөрелде, – диде Нурлат урманчылыгы җитәкчесе Рөстәм Галиев. – Минеральләштерелгән полосалар булдыру эшен дәвам итәбез.

Районның баш урманчысы әйтүенчә, Восход участок урманчылыгында тиешле техникасы белән янгын сүндерү-химик станция бар, моннан тыш, патрульлек өчен мобиль төркемнәр булдырылган. Алар басудагы коры үлән януын теркәгәннәр, урман янында исә андый фактлар булмаган. Рөстәм Галиев әйтүенчә, тулаем алганда, район урманнарында соңгы биш ел дәвамында ут чыгулар булмаган. Бу, әлбәттә инде, урманчыларның янгын сүндерү службалары белән күмәк тырышлыгы нәтиҗәсе, алар май бәйрәмнәрендә дә кизү торуларын туктатмаячак.

– Моңа ирекле янгын дружиналары, 125нче янгын частеның личный составы, безнең күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге җәлеп ителәчәк, – диде Әлмәрис Талипов. – Ә күзәтү җирдән генә түгел, космостан да алып барылачак. ГЛОНАСС системасы ут чыгу урынына тап булса, шул арада ук аның координатларын диспетчерлык хезмәтенә юллый. Раслау алганнан соң, янгын сүндерү расчеты янгын урынына чыга.

Метеостанциядә әйтүләренчә, май аенда температура 25 градуска кадәр җылыначак. Дачада да ял итәргә, эшләп алырга була. Тик янгынга каршы кагыйдәләрне генә онытмагыз. Чөнки кайчагында мондый ваемсызлык зур бәла китерергә мөмкин. Мисал өчен, бу бәйрәм көннәрендә “Алмалык”, “Шикәрче”, “Тимер юлчы” бакчачылык ширкәтләрендә ут чыгу очраклары булган.

– Бу дача участоклары шәһәр эчендә, һәм ут тиз арада торак корылмаларга да үрли ала, – диде 125нче янгын часте начальнигы Илһам Курамшин. – Чехов урамында яшәүчеләр 9нчы йорт янына чүп-чар җыйганнар да аңа ут төрткәннәр. Әгәр дә бер ханымның уяулыгы булмаса, янгын чыгу ихтималы бик зур иде. Әлеге хатын-кыз бер үзе утны сүндерер өчен өеннән су ташый, ә күршеләре читтән тыныч кына бу хәлне күзәтеп торалар.

Кайчагында утны сүндерер өчен бер чиләк су, ә дөрләтеп җибәрер өчен бер тамчы ваемсызлык та җитә шул.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ВАКЫЙГА




ЧЕРНОБЫЛЬЧЕЛӘРНЕ ИРИНА АФАНАСЬЕВА КОТЛАДЫ

# Онытылырлык түгел

**Чернобыль АЭСы һәлакәтләрен ликвидацияләүдә катнашучыларны хөрмәтләү көнендә “Встреча” кафесында узган чарада Чернобыль һәм “Маяк” аварияләре корбаннарын бер минут тынлык белән искә алдылар.**

Чернобыль АЭСы һәм “Маяк” һәлакәтләрен ликвидацияләүдә катнашкан нурлатлылар бүген 33 кеше исәпләнә. 1956 елны армиягә алынган нурлатлы Гаяз Усманов һәм Наил Әхмәдиевка “Маяк” производство берләшмәсендә һәлакәтләрне ликвидацияләүдә катнашырга насыйп булган.

- Әлеге коточкыч фаҗигадән соң 58 ел вакыт узса да, гомеребезгә зур зыян китергән афәтне онытып булмый, - ди Наил ага. – Ул вакытта мин зенит-ракета гаскәрләрендә хезмәт итә идем. Авария төшке аш вакытында, без постта торганда килеп чыкты. Һаваны кап-кара болыт чолгап алды. Әлеге һәлакәт калдыкларын җыештыруга дүрт еллап гомеребезне бирдек.

- Кызганыч, минем тормыш иптәшемә Җиңүнең 70 еллыгын күрергә насыйп булмады, - ди Гөлсирә апа Усманова. – Әлеге атом радиоактив һәлакәтләре бик күп кешенең сәламәтлегенә, тормышына зыян салды. Иптәшем үзе күргәннәрне күз яшьләрсез сөйли алмый иде.

19 ел гомер узганнан соң шундый ук һәлакәт Чернобыль АЭСында килеп чыга.

- 29 ел элек атом электростанциясе вакыйгаларында нурлатлылар да катнаштылар, – диде социаль яклау идарәсе начальнигы Ирина Афанасьева. – Әлеге һәлакәтләрнең нәтиҗәләре сезнең сәламәтлек, тормышыгыз бәрабәренә тәртипкә кителде. Сезгә район башлыгы Равил Кузюровның олы рәхмәтләрен җиткерәм. Кызганыч, чернобыльчеләрнең күбесе арабызда юк инде. Бүген без бергә аларны искә алу, андый һәлакәтләрнең башка кабатланмавын теләү өчен дә җыелдык.

**Зилия ӘКСАНОВА**

# Музыка хакимлек итте

СӘХНӘ




**Узган атнада Мәдәният сараенда Нурлат балалар сәнгать мәктәбенең зур хисап концерты тулы зал һәм көчле алкышлар астында үтте.**

Быел үзенең ярты гасырлык юбилеен билгеләп үтүче сәнгать мәктәбе коллективы хисап концертын Җиңүнең 70 еллыгына багышлады. Анда мәктәпнең Халыкара, Бөтенроссия, регионара бәйгеләре җиңүчеләре чыгыш ясады, мәктәп директоры Валентина Тяжова аларга бүләкләр һәм рәхмәт хатлары тапшырды.

Халык уен кораллары оркестры, аерым номерлар белән башланып киткән концерт вокал һәм хореография коллективлары, нәфис сүз осталарының чыгышлары белән дәвам итте. Классик, халык музыкасы, заманча көйләр һәм биюләр дә кергән өч сәгатькә якынлык программаны тамашачылар бер тында кабул иттеләр һәм балаларда музыкага мәхәббәт тәрбияләүче коллективка рәхмәт белдерделәр.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

ТӨЗЕЛЕШ

# Ремонт сузганны яратмый

**Май бәйрәмнәрендә “НурлатЕвроСтрой” җәмгыяте үзләренең капиталь ремонт объектларындагы эшләрнең ахыргы этабына тотынды. Сәлимҗанов ур., 19, Гыйматдинов ур., 60 һәм Мәктәп ур., 50дәге йортларда алар җылыту системасын алыштыруга керештеләр.**

Бу йортларда төп эшләр төгәлләнгән инде. Мисал өчен, Сәлимҗанов урамындагы йортның түбәсен әле яңа елга кадәр үк ремонтлаганнар. Бу вакытка суүткәргечне, канализацияне алыштырганнар, электр хуҗалыгы буенча эшләрне төгәлләгәннәр, подъездлардагы стеналарны буяганнар, идәннәргә плитка түшәлгән. Биредә яшәүчеләр башкарылган эшләрдән канәгать калганнар.

– Бик пөхтә эшләделәр, – ди беренче каттагы фатир хуҗасы Арина Емельянова. Шуңа да подрядчылар эшләрнең бу этабын да намуслы башкарырлар дип өметләнә. Чөнки беренче каттагылар өчен җылыту системасы аерата зур роль уйный бит. – Безнең фатир почмакта, моңа кадәр җылыту системасы начар эшли иде, фатирыбыз да салкын булды.

Ә менә өченче катта яшәүче Мөршидә Ибраһимованы кайчандыр түбә борчыган.

– Гел су үтә иде, яңгыр вакытында кухня һәм залга ләгән-чиләкләр куеп тордык, – ди ул. – Хәзер бу проблема юк.

Бу йортта яшәүчеләр подрядчыларның тырышлыгыннан канәгать, әмма алар тулаем йортның торышы өчен борчыла” – аңа 34 ел икән инде. Стеналарда ярыклар да бар, җил дә үтә, диләр. Алар йортны тышлауларын телиләр. Подрядчылар да моны сөенеп башкарыр иде, әмма монысы инде алардан тормый.

Ә җылыту системасына килгәндә, мастер-прораб Андрей Пушкин әйтүенчә, моның өчен аларга 3 атна кирәк булачак. Аннан инде объект тулысынча тапшырылган, дияргә була.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ҖИТЕШТЕРҮ

# Мондый кирпеч ясаганнары юк иде әле

**Пушкино поселогы артындагы сөрелгән җир үз сәгатен көтеп ята.**

Аның авыл хуҗалыгы культурасы үсәчәк соңгы язьдыр бу, мөгаен. Эш шунда, уңдырышлылыгыннан тыш, бу җир балчык чималына да бай әле. Ә бу кирпеч җитештерү мөмкинлеге бирә. Тик бездә кирпеч заводы бар, дияргә ашыкмагыз әле. Әлегә барлык эшләр дә өйрәнү стадиясендә. Шул исәптән завод төзелеше дә: аны кору өчен вариант буларак шәһәрдә тагы бер участок каралса, бу урында сыйфатлы балчыкның зур запасы булу сәбәпле, чимал белән тәэмин итү ноктасы төгәл билгеләнгән.

Мондый карар бер көн эчендә генә кабул ителмәгән, әлбәттә. Урынын өч еллап элек хәл иткәннәр. Ә беренче май бәйрәмнәре алдыннан биредә заводның проектчылары, подрядчысы булып киттеләр. Район башлыгы Равил Кузюров урында ук эшче киңәшмә үткәрде. Сораулар күп, ни дисәң дә, масштаблы проект бит. Өстәвенә, кирпеч заводы гади түгел, кем әйтмешли, алтын дияргә була: биредә керамогранит, керамик һәм клинкерлы кирпеч җитештерү планлаштырыла. Республикада клинкерлы кирпеч җитештерүче завод бөтенләй юк, иң якыны Балтыйк буенда. Шулай да район башлыгы бер төргә генә басым ясамаска, ихтыяҗны өйрәнергә кирәк, диде. Бу киләчәккә планнар булачак, ә әлегә...

– Төгәл координаталарны билгеләргә, разбивка ясарга, авыл хуҗалыгы предприятиеләре, нефтьчеләр белән кайбер мәсьәләләрне хәл итәргә – биредән торба үткәргечләр, башка коммуникацияләр үтмиме, – диде район башлыгы, һәм бүгенге киңәшмәнең бурычы – кыска срокларда проект документлары әзерләү, дип билгеләп үтте. Киңәшмәдән соң, Равил Әфраимович мондый ниятнең кайдан чыкканлыгы белән уртаклашты.

– Күптән түгел генә төрек коллегаларыбыз белән Нурлат территориясендә кушма предприятие булдыру мәсьәләсенә ачыклык керттек, – диде ул. – Хәзер оештыру эшләренең техник моментларын хәл итә башлыйбыз. Беренче чиратта, бу – техник-икътисади нигез. Икенче этап – заводның проектын булдыру. Исәпләүләр буенча, завод, республикада башка кирпеч заводлары булуга да карамастан, бик рентабельле булырга тиеш, сату базары зур, моннан тыш, Нурлат географик яктан да җайлы урнашкан. Кирпеч заводында 100ләп эш урыны булдырылыр, дип планлаштырыла, ә җитештерү елына 30-50 млн. кирпеч дип ниятләнә.

Эшче киңәшмәдән соң, кирпеч заводының проекты белән шөгыльләнүче Казанның "Нерудэксперт" фирмасы һәм "ГородСтрой" подряд оешмасы вәкилләре фикер алышуны дәвам иттеләр.

– Көн тәртибенә без бер мәсьәләне чыгардык – кирпеч заводын проектлау һәм төзү, – диде "ГородСтрой"ның баш инженеры Салих Мөлеков. – Барлык мәсьәләләрне дә хәл иткәч, быелның 15 июненә кадәр бүленгән җир участогын һәм чимал базасын геологик өйрәнү уздырырга карар иттек. Шулай ук уртак көч белән кирпеч заводын проектлау буенча рекомендацияләр бирү өчен лаборатор-технологик тикшеренүләр үткәрергә, бизнес-планны һәм башка чараларны башкарырга туры килә.

Нурлат чикләренең киңәюен дә сизми калып булмый. Яңа төзелүче күпфатирлы һәм шәхси йортлар да шуны раслый. Яңа буын төзелеш материалларының пәйда булуы да сер түгел. Тик менә алар бездә җитештерелми, бу исә материалның бәясендә чагылыш таба. Ауропада киң таралган клинкерлы кирпеч тиздән бездә дә җитештерелә башлар һәм нурлатлылар өчен яңа мөмкинлекләр ачар, дип өметләник.




РАВИЛ КУЗЮРОВ УРЫНДА УК ЭШЧЕ КИҢӘШМӘ ҮТКӘРДЕ

Сирень СӘМӘРХАНОВА

БЕЗНЕКЕЛӘР

# Гаилә даны битен нурлатлылар да яза



НУРЛАТТАН ГАИЛӘ ДАНЫ БИТЕН ЯЗУЧЫЛАР МӘСКӘҮДӘ

**Нурлатлылар Халыкара "Страница семейной славы" бәйгесенә тәкъдим иткән сигез иҗади эш арасыннан алтысы I, II дәрәҗә Дипломнар һәм Мактау грамоталары белән билгеләп үтелде, шул исәптән ике автор интернет-журналист Владимир Сухомлинның истәлек медален алды.**

Конкурс лауреатлары Дания һәм Адилә Сибгатовалар, Аяз, Гөлназ һәм Гөлүсә Әһлиуллиннар, Илья Кузнецов һәм Маргарита Литта күптән түгел Мәскәүгә барып, интернет-проектның йомгаклау чараларында катнаштылар. Аларны М.В.Ломоносов исемендәге Мәскәү Дәүләт Университетының исәпләү математикасы һәм кибернетика факультетында професссор Владимир Сухомлин конкурсның башка лауреатлары һәм остазлары белән бергә сәламләде. Шунда ук "Яшьләрдә ватанпәрвәрлек тәрбияләү" дип аталган халыкара фәнни-методик семинар үтте. Семинарга илнең төрле почмакларыннан җыелган катнашучылар үзләренең конкурс эшләре һәм проектлары турында сөйләделәр. Россия фәннәренең төп сарае саналган уку йортының бөеклеге тәэсир итми калмады, чыгышлар югары эмоциональ нотада булды. Профессор Сухомлин лауреатларның үз эшләрендә яктыртылган һәм ата-бабалары, якташларының каһарманлыклары белән бәйле вакыйгаларны күп тапкырлар йөрәкләре аша үткәрүләре сизелә, дип билгеләде. Ул яшь патриотлар тәрбияләүдә укытучы-остазларның, шул исәптән газетабызның җәмәгать корреспонденты, проектта күп тапкырлар катнашкан Дания Сибгатованың да ролен аерым билгеләп үтте. Форум "Страница семейной славы" интернет-конкурсын Бөек Җиңүнең юбилей елында үткәрүгә бәйле мәсьәләләр хакында сөйләшү белән тәмамланды. Шунда ук конкурс лауреатларының иҗади эшләреннән торган күптомлы җыентыкны бастыру перспективалары турында да сүз булды. Ул киләчәк буыннарга Россиянең тере тарихын мирас итеп калдыручы җыентык булачак бит. Нурлат гимназиясе чыгарылышлары Адилә Сибгатова белән Гөлфәр Мәхмүтовның эшләре шул исемдәге басмага кертелгән дә инде.

Икенче көнне, 24 апрельдә, Россия журналистикасының төп символы булган Никитин бульварындагы борынгы особняк кунакларга үз ишекләрен ачты. Биредә Пушкин үзенең иҗат кичәләрен үткәрә торган булган. Әлеге Үзәк журналистлар йортында "Святая память" дип аталган Милли Медиафорум үтте, һәм конкурста җиңүче 220 кеше бүләкләнде. Концерт залы шыгрым тулы иде, һәм бу конкурста катнашучыларның саны елдан-ел арта баруы турында сөйли. Медиафорумны проектның фәнни җитәкчесе, жюри рәисе профессор Владимир Сухомлин ачып җибәрде. Журналистлар берлеге исеменнән кунакларга оешма секретаре Рафаэль Гусейнов мөрәҗәгать итте. Проектның чираттагы этабы тәмамлану белән барысын да котлап, Мәскәүнең ветераннар Советы вәкиле Иван Харьков мөрәҗәгать итте, үз чыгышында ул башкарылган эшләрнең өлкән буынның батырлыкларын мәңгеләштерүдә мөһим булуын ассызыклады. Югославия партизаны, танылган Черногория шагыйре Йоле Станишич, Халыкара славян журналистлары берлеге әгъзасы Мария Веселовская-Томаш, танылган язучы һәм публицист Александр Бобровның мөрәҗәгатьләре дә залдагыларны битараф калдырмады. Аралашу мизгелләрен "Диалог" театрының музыкаль-шигъри тамашасы бизәде, аларга залдагылар да кушылды. Алар чараның программасы тәмамлангач та таралышырга ашыкмадылар, Журналистлар йорты интерьеры фонында мәртәбәле кунаклар белән истәлеккә фотога төштеләр, тәэсирләрен уртаклаштылар һәм иҗади хезмәттәшлек итәргә дип сүз куештылар. Барлык катнашучылар да бәйрәм бик уңышлы чыкты, дип билгеләп үттеләр. Һәм инде берничә көннән – 9 майда Җиңүнең 70 еллыгы көнендә "Страница семейной славы" проектының яңа конкурс циклы башлана.

Маргарита ЛИТТА

ТИКШЕРҮ

## ЧИРАТ – АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕНДӘ

**Һәрбер техника елга бер тапкыр техник карау үтәргә тиеш. Шул максаттан Гостехнадзорның Нурлат районы һәм Нурлат шәһәре идарәсендә үзйөрешле машиналар һәм таккычларга техник карау үтүне алдан билгеләнгән һәм расланган график буенча алып баралар.**

Гыйнвар аенда кар машиналары һәм квадроцикллар тикшерелсә, апрель аенда авыл хуҗалыгы предприятиеләре техникасына тулысынча техник карау үткәрделәр, бу көннәрдә шәһәрнең оешма-предприятиеләренә чыгулар дәвам итә. Ә 13 майдан авыл җирлекләрендә яшәүче физик затларның техникасына еллык техник караулар башлана.

- Авыл җирлекләренә график буенча 13 майдан 22сенә кадәр чыгачакбыз. Техник карау үтү өчен билгеләнгән вакытка авыл җирлекләре башкарма комитетлары янына килергә кирәк булачак, - ди идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы Дмитрий Кудряшов. – Техник караулар барышында документларның, иминият полисларының тәртиптә булуына, тормоз, идарә системасының, электр җиһазларының төзеклегенә һәм башкаларга зур игътибар биреләчәк.

Техник карау үтүнең графигы белән исә Нурлат муниципаль районының nurlat.tatarstan.ru рәсми сайтында танышырга яисә Гостехнадзор идарәсенә шалтыратып белешергә була.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

# Геройларның исеме онытылмасын

ПАРТИЯ ПРОЕКТЫ

**"Бердәм Россия" партиясенең Татарстан төбәк бүлеге игълан иткән "Герой исемендәге урам" проекты һәм җирле бүлекчәнең "Ветеранга канәфер чәчәге" акциясенә кушылып, "Мәктәп микрорайоны" башлангыч бүлекчәсе әгъзалары "Шифа" сәүдә үзәге янында акция оештырды.**

- "Герой исемендәге урам" проектында без шәһәрлеләргә якташыбыз, Дан орденының тулы кавалеры Павел Егорович Михеев турында сөйләргә булдык, - ди бүлекчә секретаре Ольга Пакшина. – Шәһәребезнең Көнчыгыш микрорайонында аның исемен йөрткән урам бар.

Акция барышында бүлекчә әгъзалары шәһәрлеләргә Павел Михеев турында сөйләп кенә калмадылар, аның батырлыклары турында язылган брошюралар һәм Георгий тасмалары да тараттылар.

- Павел Михеевның исеме таныш булса да, аның батырлыкларыннан бик аз хәбәрдар идек, - диделәр бердәмросслар кулыннан бүләкләр алган Даутовлар. Ә менә Денис Егоров Нурлатта бер еллап кына яши әле. Дан орденының тулы кавалеры Павел Михеев турында да бирелә белде һәм мондый акцияләрне оештыру кирәк, дигән фикерен җиткерде. ДЮСШның футбол буенча тренеры Юрий Никитин исә батырның туган авылы Егоркинода менә инде 5 ел рәттән Павел Михеев истәлегенә футбол буенча районның ачык турниры үткәрелүен дә хәбәр итте.

- Футболчылар анда ел да теләп катнашалар. Ул быел 1 майга билгеләнгән, - диде ул.

Акция берәүне дә – өлкәннәрне дә, урта яшьтәгеләр һәм балаларны да битараф калдырмады, мәгълүматларны игътибар белән тыңлап, рәхмәт әйтеп киттеләр.

Башлангыч бүлекчә әгъзалары 9нчы мәктәп укучылары белән берлектә "Ветеранга канәфер чәчәге" акциясе кысаларында 50 данә Җиңү чәчәге дә ясаганнар, аларны 9 Майда ветераннарга өләшәчәкләр. Шулай ук "Балалар илне ясый" бәйгесендә дә теләп катнашканнар.

Лилия МӨБАРӘКШИНА




МӘГЪЛҮМАТ

**"Герой исемендәге урам" проектына шәһәрнең "Тимер юлчылар", "Юность" һәм "Дружба" микрорайоннары башлангыч бүлекчәләре дә кушылды. Алар шәһәрлеләргә Советлар Союзы Геройлары Анатолий Кузнецов, Николай Синдряков һәм Николай Козлов турында сөйләделәр.**


ТРЕБУЕТСЯ

*кулинар-кондитер. Т. 8-927-243-71-76.
*в магазин «Автомасла» слесарь, зарплата достойная. Т. 8-9274-426-362.
*организации рабочий (ая) по благоустройству территории. Т. 8-917-896-98-45.
*парикмахер. Т. 8-937-287-68-88.
*продавец на универсальный рынок. Режим работы с 08.00 до 14.00. Т. 8-937-580-47-91.
*старший повар, повар, товаровед. Т. 2-32-99.
*ухаживающая (-ий) за женщиной 84 года, с проживанием. Т. 8-927-453-71-89.
*рабочие. Т. 8-937-570-64-24.
*ухаживающая (ий) за женщиной с проживанием. Т. 8-927-461-98-97.

КУПЛЮ

*Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.
*дойных коров. Т. 8-927-678-41-17.
*ульи, б/у. Т. 8-987-911-56-23.
*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.
*УАЗ. Т. 8-927-443-98-98.
*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.
*б/у кресло в парикмахерскую. Т. 8-927-470-68-61.

СНИМУ

*1-комнатную квартиру рядом со школой №10. Т. 8-937-774-55-49.
*2-комнатную квартиру в мкр. Яшлек. Т. 8-937-520-94-24
*помещение. Т. 8-960-041-96-86.

ОБМЕН

*Обменивается трехкомнатная квартира на двухкомнатную с доплатой. Варианты. Т. 8-927-448-06-58.

СДАЮТСЯ

*квартира посуточно. Т. 8-927-406-11-06.
*парикмахерские места. Т. 8-927-403-91-39.
*квартира посуточно, командировочным. Т. 8-927-456-05-69.
*квартира. Т. 8-927-474-46-16.
*2-комнатная квартира возле церкви. Т. 8-927-443-66-84.
*2-комнатная квартира, г. Казань, ул. Хади Такташ,119, на 4 этаже, долгосрочно. Т. 8-937-524-27-75.
*1-комнатная квартира в центре, без мебели. Т.: 2-03-69, 8-937-288-51-78.

ЖБ КОЛЬЦА. ДОСТАВКА. КРАН-МАНИПУЛЯТОР. Т. 8-927-403-51-99.

ТЕПЛИЦЫ РАЗНЫХ РАЗМЕРОВ ОКРАШЕННЫЕ, ОЦИНКОВАННЫЕ, Т.: 8-937-579-24-24, 8-987-409-27-06. КРЕДИТ (АО «ОТП БАНК», АО «АЛЬФА-БАНК»).

**22 апреля случилось ДТП со смертельным исходом (сбили женщину в красной ветровке, в черных брюках). Очевидцев просим откликнуться и позвонить по т. 8-927-496-68-95. Пожалуйста, не оставайтесь равнодушными.**

ЖАЛЮЗИ. 8(84345) 2-02-50, 8-927-428-84-33.

НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ любой сложности. 8-9600-33-77-55.

ЦЕМЕНТ. УСЛУГИ КРАНА-МАНИПУЛЯТОРА. Т. 8-927-248-52-21.

ОАО «НУРЛАТСКОЕ АТП» 22 МАЯ 2015 ГОДА В 10.00 ПРОВОДИТ ГОДОВОЕ ОБЩЕЕ СОБРАНИЕ АКЦИОНЕРОВ ПО АДРЕСУ: Г.НУРЛАТ, УЛ. ШКОЛЬНАЯ, Д. 31.
ПОВЕСТКА ДНЯ:
1. ИЗБРАНИЕ СЧЕТНОЙ КОМИССИИ.
2. УТВЕРЖДЕНИЕ ГОДОВОГО ОТЧЕТА ОБЩЕСТВА ПО ИТОГАМ ФИНАНСОВОГО 2014 ГОДА, БУХГАЛТЕРСКОЙ ОТЧЕТНОСТИ, В ТОМ ЧИСЛЕ ОТЧЕТОВ О ПРИБЫЛЯХ И УБЫТКАХ, О ВЫПЛАТЕ ВОЗНАГРАЖДЕНИЯ ЧЛЕНАМ СОВЕТА ДИРЕКТОРОВ.
3. ИЗБРАНИЕ СОВЕТА ДИРЕКТОРОВ ОБЩЕСТВА.
4. ИЗБРАНИЕ РЕВИЗИОННОЙ КОМИССИИ ОБЩЕСТВА.
5. ВНЕСЕНИЕ ИЗМЕНЕНИЙ В УСТАВ ОБЩЕСТВА.
6. УТВЕРЖДЕНИИ АУДИТОРА ОБЩЕСТВА.
7. РАССМОТРЕНИЕ ВОПРОСА О ВЫХОДЕ ИЗ СОСТАВА УЧРЕДИТЕЛЕЙ ООО «ДИЗЕЛЬ».
СПИСОК ЛИЦ, ИМЕЮЩИХ ПРАВО НА УЧАСТИЕ В СОБРАНИИ, СОСТАВЛЕН НА 22 АПРЕЛЯ 2015 Г. С ИНФОРМАЦИЕЙ ДЛЯ АКЦИОНЕРОВ МОЖНО ОЗНАКОМИТЬСЯ С 18 ПО 21 МАЯ 2015 ГОДА С 8.00 ДО 16.00 ПО АДРЕСУ: Г.НУРЛАТ, УЛ. ШКОЛЬНАЯ, 31.

ВНИМАНИЕ!
ВСЕМ РУКОВОДИТЕЛЯМ ТСЖ, УПРАВЛЯЮЩИХ КОМПАНИЙ, ПРОМ. ПРЕДПРИЯТИЙ И ДРУГИМ ПОТРЕБИТЕЛЯМ, ПОДКЛЮЧЕННЫМ К ТЕПЛОВЫМ СЕТЯМ КОТЕЛЬНЫХ ОАО «НТС»!
ОАО «НУРЛАТСКИЕ ТЕПЛОВЫЕ СЕТИ» СООБЩАЮТ, ЧТО СОГЛАСНО ПЛАНА-ГРАФИКА С 12 МАЯ 2015 Г. БУДЕТ ПРОИЗВОДИТЬСЯ ОПРЕССОВКА МАГИСТРАЛЬНЫХ НАРУЖНЫХ ТЕПЛОТРАСС ДАВЛЕНИЕМ 12 АТМОСФЕР. ВО ИЗБЕЖАНИЕ ПОРЫВОВ ВНУТРИДОМОВОЙ ОТОПИТЕЛЬНОЙ СИСТЕМЫ, ВАМ НЕОБХОДИМО НА ГРАНИЦЕ РАЗДЕЛА ЭКСПЛУАТАЦИОННОЙ ОТВЕТСТВЕННОСТИ ЗАКРЫТЬ ЗАПОРНУЮ АРМАТУРУ И УСТАНОВИТЬ ЗАГЛУШКИ НА ВВОДАХ В ЗДАНИЯ (ЖИЛЫЕ ДОМА). ПРИ ОБНАРУЖЕНИИ ПОВРЕЖДЕНИЙ НАРУЖНЫХ ТРАСС СООБЩИТЬ ПО ТЕЛ.: 2-33-75, 2-39-76.

**Уважаемые предприниматели!**
Министерством экономики РТ объявлен Конкурсный отбор субъектов малого и среднего предпринимательства РТ для предоставления государственной поддержки в форме субсидий по программе «ЛИЗИНГ-ГРАНТ». Прием заявок на участие осуществляется с 23 апреля 2015г. по 22 мая 2015г. по адресу: 420021, г. Казань, ул. Московская, д.55, каб.125.
По всем возникающим вопросам Вы можете обращаться в отдел территориального развития Исполнительного комитета Нурлатского муниципального района по тел.: 2-06-69.
Подробную информацию по программе «ЛИЗИНГ-ГРАНТ» можно найти на сайте Министерства экономики РТ: www.mert.tatarstan.ru в разделе «Развитие и поддержка малого и среднего предпринимательства», «Программы поддержки предпринимательства», «ЛИЗИНГ-ГРАНТ»- «Нормативные правовые акты».

ООО «САМАРААВТОТРАНС-2000» НА ПОСТОЯННУЮ РАБОТУ ТРЕБУЮТСЯ ВОДИТЕЛИ НА ПЕРЕВОЗКУ ОПАСНЫХ ГРУЗОВ (КАТ. Е).
УСЛОВИЯ РАБОТЫ: ОПЫТ РАБОТЫ, ТРУДОУСТРОЙСТВО СОГЛАСНО ТК РФ, СОЦ. ПАКЕТ, ДОСТОЙНАЯ З/П.
ОБРАЩАТЬСЯ: САМАРСКАЯ ОБЛ., КОШКИНСКИЙ Р-Н, СТ. ПОГРУЗНАЯ, УЛ. ПЕРВОМАЙСКАЯ, Д. 114А.
ТЕЛ.: (846) 502-35-23, 8-927-746-82-29 (БОГАТОВ В.М.).

МАГАЗИН «ПЧЕЛКА» ВСЕ ДЛЯ ВЕТЕРИНАРИИ И ПЧЕЛОВОДСТВА, ПГТ АКСУБАЕВО, УЛ. КРАСНОАРМЕЙСКАЯ, 2 ВОЩИНА ПРОДАЖА И ОБМЕН (1 КГ 400 РУБ.), ИНВЕНТАРЬ И ЛЕКАРСТВА ДЛЯ ПЧЕЛ ПО НИЗКИМ ЦЕНАМ. 8-927-409-06-65.

ДОСТАВКА ПЕРЕГНОЙ, ЧЕРНОЗЕМ, ГРУНТ, ПЕСОК, ПГС, ДРОВА КОЛОТЫЕ. 8-937-280-94-84.

Реклама
**Даём заём!**
**ООО «Заем-16» поздравляет жителей города и района с праздником - 70-летием Победы и проводит акцию -**
*с 01.05.2015 г. по 31.05.2015 г. снижает процентные ставки на краткосрочные микрозаймы с 1,5% на 1% и микрозаймы с 9% на 8%.*
г.Нурлат, ул. К.Маркса, 41, ТД "Персона", офис 108.тел.(84345) 2-32-92
ООО «Заем-16» свидетельство о внесении сведений в государственный реестр микрофинансовых организаций, ФСФР РФ за №651303392003211 от 21.05.2013 г. ООО «Заем-16» выдает займы при положительном рассмотрении заявки: до 10000 руб. на срок от 7 до 45 дней под 1% в день, до 30000 руб. на срок от 1 до 18 месяцев под 8% в месяц из расчета начисления % на остаток суммы ежемесячно, до 300000 руб. на срок от 1 до 18 месяцев под залог автомобиля, под 8% в месяц из расчета начисления % на остаток суммы ежемесячно. За каждый день просрочки пенни 0,1% суммы к оплате. Данное предложение не является публичной офертой. Организатор: ООО «Заем-16».

В ЦЕНТРЕ С. ЧЕЛНО-ВЕРШИНЫ ПРОДАЕТСЯ ИЛИ СДАЕТСЯ В АРЕНДУ МАГАЗИН, ОБЩАЯ ПЛОЩАДЬ 360 КВ.М. Т. 8-927-730-66-92.

«УДАЧА»
НАЧИНАЕТСЯ НАБОР ГРУПП ДЛЯ ОТДЫХА В СОЧИ (ВАРДАНЕ) И КРЫМ (ФЕОДОСИЯ) ВЫЕЗДОМ НА ПОЕЗДЕ В ИЮНЕ И ИЮЛЕ МЕСЯЦЕ. 8-9274-17-17-10.

ЖАЛЮЗИ. Все виды. Быстро. Замер и установка бесплатно. 8-927-672-01-17.

ТЕЛӘСӘ НИНДИ КАТЛАУЛЫЛЫКТАГЫ ТАРТТЫРЫЛМА ТҮШӘМНӘР, ЖАЛЮЗИ
Профессиональ монтажлау.
Түбән бәяләр.8-937-527-43-15.

*РУКОВОДСТВО И СЛУЖБА ТАКСИ «НУРЛАТ» ПОЗДРАВЛЯЮТ ВСЕХ ВЕТЕРАНОВ С ПРАЗДНИКОМ ДНЕМ ПОБЕДЫ И ДАРИТ С 9 ПО 15 МАЯ БЕСПЛАТНЫЙ ПРОЕЗД НА ТАКСИ, ПРИ НАЛИЧИИ УДОСТОВЕРЕНИЯ.*
***Подробности по т. 2-11-11.***
*ИП Мухаметшина Л.А.*

ООО «МИР КРОВЛИ»
РЕАЛИЗУЕТ
ПРОФНАСТИЛ С9, С20, С21, НС44, Н60, Н75 (ОЦИНКОВАННЫЙ И ОКРАШЕННЫЙ), ДЛИНА ДО 12 МЕТРОВ, МЕТАЛЛОЧЕРЕПИЦУ, МЕТАЛЛОСАЙДИНГ, МЕТАЛЛОШТАКЕТНИК, ПРОФИЛЬНУЮ ТРУБУ, ГЛАДКИЙ ЛИСТ, ДОБОРНЫЕ ЭЛЕМЕНТЫ. УТЕПЛИТЕЛЬ. ПАРОГИДРОИЗОЛЯЦИЯ. ПОЛИКАРБОНАТ. ТЕПЛИЦЫ.
ДОСТАВКА ПО ГОРОДУ БЕСПЛАТНО.
ГАРАНТИЯ НА ВСЮ ПРОДУКЦИЮ.
Т.: 8-927-826-53-32, 8-937-273-87-15, 8(84235) 2-75-35, 2-72-25.
E-MAIL: MIR-KROVLI73@BK.RU


## Совет директоров "Татнефти" обсудил итоги работы Компании в 2014 году

27 апреля 2015 года в г. Казань (Республика Татарстан) состоялось очередное заседание Совета директоров ОАО "Татнефть". Подведены итоги исполнения бюджета Компании за первый квартал текущего года, утвержден бюджет на май.

Обсуждены итоги финансово-хозяйственной деятельности ОАО "Татнефть" за 2014 год.

В прошедшем году на месторождениях Компании добыто 26 млн 223 тыс. тонн нефти, что на 0,4% выше уровня 2013 г. В эксплуатацию введены 255 новых добывающих скважин. На лицензионных месторождениях дочерних обществ за пределами Татарстана в Российской Федерации добыто 307 тысяч тонн нефти.

За отчетный период выработано и сдано 276 тыс. тонн ШФЛУ, объем добычи сбора попутного нефтяного газа составил 884 млн. кубических метров. Объем добычи сверхвязкой нефти на Ашальчинском месторождении составил 237 тысяч тонн, всего с начала разработки по состоянию на 1 января 2015 года добыто свыше 562 тысячи тонн.

Выручка-нетто (без НДС и экспортной пошлины) составила 392,4 млрд. рублей. По результатам финансово-хозяйственной деятельности получено 104 миллиарда рублей прибыли до налогообложения. Чистая прибыль составила 82 млрд. рублей. Общая сумма начисленных налогов и платежей во все уровни бюджета составила 313,8 миллиардов рублей.

На выполнение инвестиционной программы по всем видам производственной деятельности группы компаний "Татнефть" направлено 68,4 млрд. рублей, в том числе в сферу нефтедобычи - 41,6 млрд. рублей, на нефтепереработку - 18,7 млрд. рублей.

Обсуждена программа по поддержке научных исследований в области нефтедобычи и нефтепереработки во взаимодействии с ведущими научно-образовательными учреждениями, расположенными на территории Республики Татарстан.

Совет директоров рассмотрел ход выполнения инвестиционной программы. Отмечено, что вложенные инвестиции обеспечили добычу 2,2 млн. тонн нефти, что на 10% выше запланированных показателей. Наиболее эффективными стали вложения средств в следующие мероприятия: применение методов увеличения нефтеотдачи пластов, гидроразрыв пласта, одновременно-раздельная эксплуатация пластов.

На заседании заслушана информация о дивидендах по акциям "Татнефти", о годовом общем собрании акционеров общества, рассмотрен ряд других вопросов деятельности Компании.

*На правах рекламы*


В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ НАПРАВЛЕНИЯМ:

16 МАЯ 2015 ГОДА
1. ГАСТРОЭНТЕРОЛОГИЯ.
2. ВЗРОСЛАЯ И ПОДРОСТКОВАЯ ГИНЕКОЛОГИЯ.
3. СОСУДИСТАЯ ХИРУРГИЯ, НОВЫЙ РЕВОЛЮЦИОННЫЙ МЕТОД ПРИ ВАРИКОЗНОЙ БОЛЕЗНИ ВЕН, НЕ ТРЕБУЮЩИЙ ГОСПИТАЛИЗАЦИИ И НАРКОЗА. ПОМОЩЬ ПРИ СОСУДИСТЫХ ЗВЕЗДОЧКАХ.
4. КАРДИОЛОГИЯ, РЕВМАТОЛОГИЯ.
5. НЕВРОЛОГИЯ.
6. ВРАЧИ ПРОВЕДУТ НА ВЫСОКОТЕХНОЛОГИЧНОМ ОБОРУДОВАНИИ ИССЛЕДОВАНИЕ СЕРДЦА, ЭХОКАРДИОСКОПИЮ С ЦДК (ЦВЕТНОЕ ДОПЛЕРОВСКОЕ КАРТИРОВАНИЕ), ИССЛЕДОВАНИЕ СОСУДОВ ГОЛОВНОГО МОЗГА, ВЕРХНИХ И НИЖНИХ КОНЕЧНОСТЕЙ.

17 МАЯ 2015 ГОДА
1. ГИНЕКОЛОГИЯ, РЕПРОДУКТОЛОГИЯ. РЕШЕНИЕ ПРОБЛЕМ ПРИ БЕСПЛОДИИ. ВЕДЕНИЕ БЕРЕМЕННОСТИ.
2. ДИЕТОЛОГИЯ.
3. ЭНДОКРИНОЛОГИЯ.
4. ОТОЛАРИНГОЛОГИЯ.
5. АНДРОЛОГИЯ. ПОМОЩЬ ПРИ ЭРЕКТИЛЬНОЙ ДИСФУНКЦИИ, ЗППП, МУЖСКОМ БЕСПЛОДИИ, ХР.ПРОСТАТИТЕ, АДЕНОМЕ ПРЕДСТАТЕЛЬНОЙ ЖЕЛЕЗЫ.
6. АЛЛЕРГОЛОГИЯ. ИММУНОЛОГИЯ. РЕШЕНИЕ ПРОБЛЕМ ПРИ БРОНХИАЛЬНОЙ АСТМЕ, АЛЛЕРГИЧЕСКИХ ДЕРМАТИТАХ, КОЖНЫХ ЗАБОЛЕВАНИЯХ.
7. ВРАЧИ ПРОВЕДУТ ИССЛЕДОВАНИЯ ОРГАНОВ МАЛОГО ТАЗА, ПЛОДА НА 1,2 И 3 ТРИМЕСТРАХ.

Реклама

КДЦ ПРЕДЛАГАЕТ УСЛУГИ ПО ДМС ЧЕРЕЗ НУРЛАТСКИЙ ФИЛИАЛ СК «ЧУЛПАН». РЕЗУЛЬТАТЫ ОБСЛЕДОВАНИЯ ПРИНИМАЮТСЯ В БМСЭ.
СПРАВКИ И ПРЕДВАРИТЕЛЬНАЯ ЗАПИСЬ ПО Т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.
ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.

**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста**